**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының 8 сыйныфында укучылар өчен олимпиада сораулары**

Үткәрү вакыты 90 мин.

## I бүлек

Түбәндә тәкъдим ителгән әсәрләр янына авторларын язып чыгыгыз

1. “Туган ягым – яшел бишек” повесте ______________________________
2. “Бер үгет” шигыре ____________________________________
3. “Сөннәтче бабай” повесте _____________________________________
4. “Беренче театр” комедиясе _____________________________________
5. “Ак чәчәкләр” романы _____________________________________

## II бүлек

Түбәндә тәкъдим ителгән юлларны укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез

Мин күп күрдем филдәй кешеләрне:
Киң күкрәкле, тимер бәдәнле.
Тик күрәсе иде эше белән
Кеше булган иң чын адәмне.
Кем сокланмас көчкә, тимер сынса
Һәм су чыкса баскан эзеңнән.
Тик ни файда, көчең филдәй булып,
Эшең булса чыпчык тезеннән.
Эзе калсын керсез намусыңның,
Ни үтсә дә синең кулыңнан.
Көчлелегең белән горурланма!
Кешелегең белән горурлан!
Һәр адымыңда синең туры акыл,
Көчле йөрәк эзен күрсеннәр,
Кылыч белән түгел, турылык һәм
Чынлык белән көчле кешеләр.
Син яшәмә җирдә файдасыз бер
Түмгәк булып тигез урында.
Янып калсын гомрең, маяк булып
Үзеңнән соң килгән буынга.
Утта булган балчык кире купмас,
Эштә булган тимер тутыкмас.
Эш күрсәткән ирне ил онытмас,
Каберенә эзне суытмас.

1. Шигырьнең авторын һәм исемен күрсәтегез

2. Шигырьдәге төп хисне билгеләгез

3. Шигырьдә кулланылган троплар, стилистик фигураларны күрсәтегез

**III бүлек**

Повесть жанрына хас үзенчәлекләрне атагыз. Мисал яки мисаллар ярдәмендә фикерләрегезне дәлилләгез.

## IV бүлек

| Яраткан язучыгызның иҗат портретын һәм иҗат лабораториясен тудырыгыз. IV бүлек биремenә җавапны күрсәтелгән юнәлеш буенча бер битлек итеп, инша рәвешендә языгыз |
|---|

1. Әдип яшәгән чор________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

2. Әдәбиятка алып килгән яңалыгы ____________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

3. Әсәрнең (әсәрләрнең) жанры, күтәрелгән төп идея-фикерләр

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

4. Сез өйрәнгән әсәрдә (әсәрләрдә) автор иҗатына гына хас милли үзенчәлекләр

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________